**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023 елның “29” ноябре 3763 номер

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының «Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына һәм канализация чистарту корылмаларына керә торган ташландык суларның үзлекләре һәм ташландык суларда пычраткыч матдәләр концентрациясе күрсәткечләренең рөхсәт ителгән кыйммәтләре нормаларын раслау турында»2023 елның 15 сентябрендәге 2161 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“ «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге 644 номерлы кайбер актларына һәм «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» " Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының 181 нче пункты нигезендә Лаеш муниципаль районы башкарма комитеты **карар бирә**:

1. «Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына һәм канализациянең чистарту корылмаларына керә торган агып төшүче суларның үзлекләре күрсәткечләренең һәм агып төшүче матдәләрнең концентрацияләренең мөмкин булган нормаларын раслау турында» 2022 елның 15 сентябрендәге 2161 номерлы карарга 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.О. Солягинга йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **А.Г.Карсалов**

*Лаеш муниципаль районы*
*Башкарма комитетының 2023 елның* 29 ноябре
*3763 номерлы карарына*
*1 кушымта*

**Лаеш муниципаль районы территориясендә урнашкан үзәкләштерелгән ташландык суларны агызу системасына һәм канализация чистарту корылмаларына кергән агынты суларның үзлекләре һәм агынты суларда пычраткыч матдәләр концентрациясе күрсәткечләренең рөхсәт ителгән кыйммәтләре нормалары**

| **№ т/б** | **Матдәнең исеме(күрсәткеч)** | **Күрсәткечнең һәм (яки концентрациянең) максималь рөхсәт ителгән саны, мг/дм3** |
|---|---|---|
| 1 | Фильтрдан соң калган матдәләр | 300,0 |
| 2 | БПК 5 | 300,0 |
| 3 | Аммоний-ионы | 25,0 |
| 4 | ХПК (кислородны химик куллану) | 500,0 |
| 5 | Фосфатлар фосфоры | 12,0 |
| 6 | Тимер гомуми | 5,0 |
| 7 | Алюминий | 5,0 |
| 8 | Бакыр | 1,0 |
| 9 | Хлоридлар | 300,0 |
| 10 | Сульфатлар | 300,0 |
| 11 | Нефть продуктлары | 10 |
| 12 | Цинк | 1,0 |
| 13 | Марганец | 1,0 |
| 14 | СПАВ | 10,0 |
| 15 | Хром гомуми | 0,5 |